ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.58

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,58

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Базарлы Матак авылы

2022 елның 07 апреле 104№

2022 елгаТатарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы милкендә
булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның
фараз планы (программасы) турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 50 һәм 51 статьясы, 85 статьясындагы 8 пукт 4 пунктчасы, 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планын 1 нче кушымта нигезендә расларга
2. Әлки муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына 2022 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планын үтәү өчен әзерлек эшләре алып барырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының www.alkeevskiy.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Россия Федерациясенең «Интернет» челтәрендәге www.torgi.gov.ru. рәсми сайтында урнаштырырга.http://www.alkeevskiy.tatarstan.ru
4. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2021 елның 03 мартындагы “2021 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында” 36 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының бюджет, салымнар һәм финанс, җирле җыемнар, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы: А. Ф. Никошин

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2022 елның 7 апрелендәге 104 номерлы карарына 1 нче кушымта

**2022 елга Татарстан Республикасы «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планы (программасы)**

## 1Бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2022 елга Татарстан Республикасының «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) (алга таба муниципаль мөлкәт) 2001 елның 21 декабрендәге "Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында" гы 178-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнде.

1.2. 2022 елда муниципаль милекне хосусыйлаштыру муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, күчемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль милекне сатудан бюджет дефицитын каплау чыганакларын булдыруга юнәлдерелгән.

1.3. 2001елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль милекне хосусыйлаштыруны аукционда сату юлы белән башкару күздә тотыла.

## 2 Бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

2.1. 2022 елда Әлки муниципаль районы бюджетыннан финанслanучы муниципаль казнадагы һәм оешмалар файдаланмаган муниципаль милек хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.2.Хосусыйлаштырырга планлаштырылган муниципаль милек исемлеге:

| т/б № | Мөлкәтнең атамасы һәм характеристикасы | Адрес (урнашу урыны) | Файдалануга тапшыру елы, (чыккан елы) | Хосусыйлаштыруның фаразланган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Автотранспорт чарасы<br>Автомашина TAYOTA LAND CRUISER 200 Җиңел Регистрация номеры Р 226 КО 116 VIN JTMHT05J105027464 | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56 й. | 2008 | 3,4 квартал |
| 2 | Автотранспорт чарасы<br>Автобус Фиат Дукато,<br>Дәүләт № М 708 ХВ 116 RUS VIN Z7G244000AS020622 | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Түбән Әлки авылы | 2010 | 2,3 квартал |
| 3 | Автотранспорт чарасы<br>Автомашина ВАЗ 21140 LADA SAMARA Регистрация номеры<br>Р 283 АМ 116 VIN ХТА21140064142566 | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Базарлы Матак авылы | 2006 | 3,4 квартал |

## 3 Бүлек Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү муниципаль мөлкәт

3.1. Әлки муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы муниципаль милекне хосусыйлаштыру турындагы мәгълүматны оператив рәвештә бирү һәм киңрәк реклама белән тәэмин итү максатыннан әлеге фараз планын үтәү барышында, рәсми мәгълүмат чыганакларыннан тыш, бүтән массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәтеннән дә файдаланырга хокуклы.